Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

20 апрель 2022 ел № 143

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367, 2020 елның 30 октябрендәге 12, 2021 елның 11 мартындагы 36, 2021 елның 16 декабрендәге 114 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарга 2 нче кушымтада «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составы»:

а) комиссия әгъзалары вазыйфалары исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алеева Әлфия Рәис кызы - Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия секретаре;»;

«Насыйбуллина Гөлнара Насыйх кызы - Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча);

б) комиссия составыннан Белоногова О.Т, Самойлов В.И.; Шабалин О.Н чыгарырга;

в) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Котбиев Илшат Камил улын - Әлмәт муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе;

Шәйдуллина Зөлфия Рәшит кызын - Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);

Яшанин Владимир Ивановичны - Әлмәт муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы рәисе (килешү буенча).

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Н.В. Парфилова) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов